| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

10.02.2016 104-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының атмосфера һавасын саклау, шул исәптән атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләүне контрольдә тоту өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүнең административ регламентын раслау турында” 08.12.2014 № 886-п боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының норматив-хокукый актларын законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының атмосфера һавасын саклау, шул исәптән атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләүне контрольдә тоту өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүнең административ регламентын раслау турында” 08.12.2014 № 886-п боерыгына (алга таба – Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәгечә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле булган хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәү буенча административ регламентын раслау хакында”;

1 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

“1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле булган хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт

күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәү буенча административ регламентын (алга таба – Административ регламент) расларга”.

2. Аталган боерык белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының атмосфера һавасын саклау, шул исәптән атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләүне контрольдә тоту өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәгечә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле булган хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәү буенча административ регламенты”;

1.1 пунктының беренче кызыл юлын түбәндәгечә бәян итәргә:

“Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата “төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле булган хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру” дәүләт вазифасын (алга таба – дәүләт вазифасы, атмосфера һавасын саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге, дәүләт күзәтчелеге) үтәгәндә Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының (алга таба – ТР ЭТРМ) гамәл кылу вакытларын һәм тәртибен билгели.”;

1.2 пунктының дүртенче кызыл юлында “эксперт оешмалары” сүзләре алдына “Россия Федерациясенең илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләү турында законнары нигезендә аккредитацияләнгән”, ә ахырдан “(алга таба – эксперт оешмалары)” сүзләрен өстәргә;

1.3 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

“1.3. Дәүләт вазифасы түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе (Российская газета, 1993, 25 декабрь, № 237, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексы (алга таба – РФ КоАП) (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2002, № 1 (1 өлеш), 1 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

1999 елның 4 маендагы “Атмосфера һавасын саклау турында” № 96-ФЗ Федераль закон (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 1999, № 18, 2222 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2002 елның 10 гыйнварындагы “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” № 7-ФЗ Федераль закон (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2002, № 2, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында” 02.05.2006, № 59-ФЗ Федераль закон (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” 26.12.2008, № 294-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон) (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2008, № 52 (1 өлеш), 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 2 мартындагы “Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларының һәм аңа карата зыянлы физик йогынтыларның нормативлары хакында” № 183 карары (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2000, № 11, 1180 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 21 апрелендәге “Атмосфера һавасына зыянлы йогынтыларны һәм аларның чыганакларын дәүләт исәбенә алу турында нигезләмә раслау хакында” № 373 карары (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2000, № 18, 1987 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 июнендәге “Дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) мәсьәләләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын көчен югалткан дип тану хакында” № 476 карары (“Россия Федерациясе законнар җыентыгы”, 2013, № 24, 2999 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Икътисади үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге “2008 елның 26 декабрендәге “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында” 141 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Икътисади үсеш министрлыгының 30.04.2009, № 141 боерыгы) (“Российская газета”, 2009, 14 май, № 85, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 2010 елның 31 декабрендәге “Атмосфера һавасына чыгарылучы дәүләт исәбенә алынырга һәм нормага салынырга тиешле зыянлы (пычраткыч) матдә ташландыкларының чыганакларын ачыклау тәртибе турында һәм Дәүләт исәбенә алынырга һәм нормага салынырга тиешле зыянлы (пычраткыч) матдәләр исемлеге турында” № 579 боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене, 2011, № 10, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

РФ Табигать министрлыгының “Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыклары чыганаклары булган юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, һәм шулай ук атмосфера һавасындагы зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыклары күләмен һәм составын дәүләт исәбенә алу тәртибен раслау турында” 26.10.2011 ел, № 863 боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнарының норматив актлары бюллетене, 2012, № 14);

Атмосферадагы зарарлы матдә ташландыкларын инвентаризацияләү буенча күрсәтмә, СССР Госкомгидромет тарафыннан расланды. (Ленинградның “Звание” РСФСР җәмгыяте. (ЛДНТП), 1991);

Предприятиеләрдән чыгучы ташландыклардан атмосфера һавасындагы зарарлы матдә концентратларын хисаплау методикасы. ОНД-86, СССРның

гидрометеорология һәм табигый тирәлекне контрольдә тоту буенча Дәүләт комитеты тарафыннан расланды, 04.08.1986, № 192 (Ленинград гидрометеорология нәшрияты, 1987);

РД 52.04.52-85 җитәкчелек документы. “Методик күрсәтмәләр. Начар метеорология шартларында ташландыкларны җайга салу”, СССРның гидрометеорология һәм табигый тирәлекне контрольдә тоту буенча Дәүләт комитеты тарафыннан расланды, 01.12.1986 (Ленинград гидрометеорология нәшрияты, 1987);

Россия Федерациясе Табигый ресурслар министрлыгының 29.03.2012 № 05-12-47/4521 хаты нигезендә гамәлгә кертелгән Атмосфера һавасына чыгарылган пычраткыч матдә ташландыкларын хисаплау, нормага салу һәм контрольдә тоту буенча методик белешмәлек (“НИИ Атмосфера” ААҖ, Санкт-Петербург, 2012);

ГОСТ 17.2.3.02-2014 “Сәнәгать предприятиеләренең мөмкин булган пычраткыч матдә ташландыкларын билгеләү кагыйдәләре” халыкара стандарты, Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 20.03.2014 № 208-ст боерыгы белән расланды (алга таба –20.03.2014 № 208-ст боерыгы белән расланган ГОСТ 17.2.3.02-2014) (Стандартинформ, 2014);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре” турында 06.07.2005 ел, № 325 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре җыентыгы һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары”, 2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының төбәкара дәүләт экология күзәтчелеген башкаручы вазифаи затлары исемлеген раслау турында” 21.09.2011 ел, №784 карары (алга таба – 21.09.2011 ел, №784 ТР МК Карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 2011, № 40, 2038 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында начар һава шартлары чорларында атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын көйләү эшләрен оештыру турында” 22.05.2012 ел, № 407 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 2012 ел, № 41, 1325 ст.);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Газчистарткыч җайланмаларны куллану буенча гомуми таләпләр”не раслау турында” 02.08.2004 ел, №761 боерыгы (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы”, 2005, № 3, 0059 ст.);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын

үтәүнең Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының административ регламентын раслау турында” 09.12. 2013 ел, №721-п боерыгы (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы хокукый мәгълүматының рәсми порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2014, 31 гыйнвар, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).”;

1.5.2 пунктында:

3 һәм 4 пунктчаларда “министр боерыгы яки министрның беренче урынбасары әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктчада “тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәрендә” сүзләреннән соң “(булган очракта)” сүзләрен өстәргә;

1.5.3 пунктында түбәндәге эчтәлекле 8, 9 пунктчаларын өстәргә:

“8) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив-хокукый актларында билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнарына туры килми торган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

9) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган муниципаль-хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең һәм таләпләрнең үтәлешен тикшерергә.”;

1.6.1 пунктының 3 пунктчасын түбәндәгечә бәян итәргә:

“3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында үзенең тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы, алар белән, шулай ук ТР ЭТРМ вазифаи затларының аерым гамәлләре белән килешүе яки килешмәве турында күрсәтергә. Тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән, яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән ризалашмаган очракта, тикшерү актын алган көннән соң унбиш көн дәвамында язма рәвештә тикшерү актына карата һәм (яки) ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмәгә карата тулаем алганда яки аның аерым нигезләмәләренә карата ТР ЭТРМ ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшмәкәр мондый ризасызлыкларга мондый ризасызлыкларның нигезле булуын дәлилли торган документларны яки аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә килештерелгән вакытка аларны дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге), муниципаль контрольлек органына тапшырырга хокуклы. Аталган документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документлар (электрон документлар җыелмасы) рәвешендә җибәрелергә мөмкин.”;

1.7 пунктында:

өченче кызыл юлдагы “шул исәптән, атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка төрле матдә ташландыклары өчен түләүнең билгеләнгән вакытларын” сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче кызыл юлда “шул исәптән, атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка төрле матдә ташландыклары өчен түләүнең билгеләнгән вакытларын” сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы кызыл юлда “тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәрендә” сүзләреннән соң “(булган очракта)” сүзләрен өстәргә;

2.1.1 пунктта “Интернет” челтәрендә” сүзләрен “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә (алга таба – “Интернет” челтәре)” сүзләренә алмаштырырга;

2.1 таблицада:

“2.1 таблица” сүзләрен “1 таблица” сүзләренә алмаштырырга;

“Территориаль орган” графасында “Үзәк территориаль идарә” сүзләрен “Үзәк территориаль идарә (алга таба - ҮТИ)” сүзләренә алмаштырырга;

“Адрес” графасындагы “Арча штп” сүзләрен “Арча ш.” сүзләренә алмаштырырга;

2.1.5 пунктының беренче кызыл юлында “Интернет-сайтында” сүзләрен “Интернет” челтәрендә” сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктында түбәндәге эчтәлекле 2.3.2. пунктчасын өстәргә:

“2.3.2. Планлы тикшерүләр өч елга бер мәртәбәдән артмаган ешлыкта үткәрелә.”;

2.4.1 пунктының җиденче кызыл юлында “Әмернамә” сүзен “Боерык (әменрамнә)” сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктында:

икенче кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазифаи затлары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 21 сентябрендәге “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының региональ дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазифаи затлары исемлеген раслау турында” № 784 карары белән расланды”;

2.2 таблицаны көчен югалткан дип танырга;

3 бүлекне түбәндәгечә бәян итәргә:

**“3. Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә куела торган мәҗбүри таләпләр**

Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә куела торган мәҗбүри таләпләр, әлеге таләпләрне билгели торган норматив-хокукый актлар, шулай ук тикшергәндә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тапшыра торган документлар исемлеге 2 таблицада китерелде.”;

2 таблицада:

“Таләпне билгели торган норматив документ” графасының аталышын түбәндәгечә бәян итәргә:

“Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив-хокукый акт”;

3 пунктта “Тикшерү үткәргәндә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр күрсәтә торган документлар” графасында “Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләү кертү турында еллык декларацияләр” сүзләрен “Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләү турында декларация” сүзләренә алмаштырырга;

5 пункттагы “Таләпне билгели торган норматив документ” графасында “ГОСТ 17.2.3.02-2014 Сәнәгать предприятиеләренең мөмкин булган пычраткыч матдә

ташландыкларын билгеләү кагыйдәләре” сүзләрен “20.03.2014 № 208-ст боерыгы белән расланган ГОСТ 17.2.3.02-2014” сүзләренә алмаштырырга;

7.1 пунктында “Тикшерелә торган таләп” графасында “кертү” сүзе алдыннан “Иң яхшы үтемле технологияләрне кертү” сүзләрен өстәргә;

12 пунктны көчен югалткан дип танырга;

4 бүлекне түбәндәгечә бәян итәргә:

**“4. Тикшерү үткәргәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр күрсәтә торган документлар**

Юридик зат һәм шәхси эшмәкәр тарафыннан тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен күрсәтелә торган документларның (күчермәләренең) исемлеге, шулай ук мондый документларның рәвешләрен раслый торган норматив-хокукый актлар 3 таблицада китерелде.”;

3 таблицада:

аталышындагы “юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан” сүзләрен “Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан” сүзләренә алмаштырырга;

15 пункттагы “Тикшерү үткәрү өчен тапшырыла торган документ” графасында “Әйләнә-тирә мохиткә (шул исәптән транспорт чараларыннан файдаланганда) тискәре йогынты өчен түләү башкаруны раслаучы документлар: түләү йөкләмәләренең күчермәләре; әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләүне башкару буенча квартал саен тапшырылучы декларацияләр” сүзләрен “Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләү башкаруны раслаучы документлар: түләү йөкләмәләренең күчермәләре, тискәре йогынты өчен түләү турында декларация” сүзләренә алмаштырырга;

18 пунктта “Документ рәвешен билгели торган норматив-хокукый акт” графасында “ГОСТ 17.2.3.02-78 СССР Дәүләт стандарты. Табигатьне саклау. Атмосфера. Сәнәгать предприятиеләре тарафыннан мөмкин булган зарарлы матдә ташландыкларын билгеләү кагыйдәләре. (24.08.1978, №2329 СССР Дәүләт стандарты Карары белән расл.)” сүзләрен “20.03.2014 № 208-ст боерыгы белән расланган ГОСТ 17.2.3.02-2014” сүзләренә алмаштырырга;

5.1.1 пунктындагы дүртенче кызыл юлда “әмернамәсе” сүзләре алдына “министрның (министр урынбасарының)” сүзләрен өстәргә;

5.1.3 пунктының икенче кызыл юлында “ТР ЭТРМ боерыгы (әмернамәсе)” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

5.1.4 пунктында:

беренче кызыл юлда “әмернамәсе” сүзләре алдына “министрның (министр урынбасарының)” сүзләрен өстәргә;

өченче кызыл юлда “әмернамәсе” сүзләре алдына “министрның (министр урынбасарының)” сүзләрен өстәргә;

бишенче кызыл юлда “әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы кызыл юлда “электрон документлар рәвешендә” сүзләре алдына “көчәйтелгән квалификацияле электрон санлы имза белән имзаланган” сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле кызыл юл өстәргә:

“Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, ТР ЭТРМ тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхсәт ителми.”;

5.1.6 пунктында:

беренче кызыл юлда “(әмернамәсе)” сүзләре алдына “министрның (министр урынбасарының)” сүзләрен өстәргә;

алтынчы кызыл юлда “әмернамәсе” сүзләрен “министр (министр урынбасары) боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

5.1.7 пунктында:

алтынчы кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:

“Әгәр контрольлек буенча чаралар барышында контрольлек буенча чаралар үткәрү объекты булган хуҗалык яки башка төрле эшчәнлекнең законнардагы таләпләрнең бозылуына бәйле икәнлеге ачыкланса, мондый очракларны ачыклау, кисәтү һәм туктату ТР ЭТРМ вәкаләтенә карамаса, ТР ЭТРМ мондый бозулар турындагы мәгълүматны (белешмәләрне) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына (Татарстан Республикасы буенча табигатьтән файдалану идарәсе, ТР буенча Росприроднадзор идарәсе, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсе (Ростехнадзор), Татарстан Республикасы буенча Россельхознадзор идарәсе, Федераль су ресурслары агентлыгының Түбән Идел бассейны су идарәсенең ТР буенча су ресурслары бүлеге, Татарстан Республикасы буенча кулланучыларның хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе, Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, “Гидрометеорология һәм Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитен мониторинглау буенча идарә” федераль дәүләт бюджет учреждениесе) җибәрергә тиеш.”;

сигезенче кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:

“Юридик затның җитәкчесе, башка вазифаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаганда, шулай ук тикшерелә торган зат тикшерү акты белән танышып чыгуы турында язунамә бирүдән баш тартканда яки танышудан баш тартканда, акт кулга тапшыру турында белдерүнамә белән, заказлы хат итеп почта аша җибәрелә һәм ТР ЭТРМ эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган зат дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) яки муниципаль контрольлек кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә риза булганда, тикшерү акты шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ рәвешендә юридик затның җитәкчесенә, башка вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ рәвешендә тикшерелә торган затка күрсәтелгән документның алынуын

раслый торган ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган булып санала.”;

5.2.4 пунктында:

алтынчы кызыл юлны түбәндәге бәян итәргә:

“Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның, махсус тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча бәяләмә алу кирәк булса, тикшерү акты контрольлек буенча чаралар тәмамланганнан соң өч эш көненнән артмаган вакытта төзелә һәм юридик затның җитәкчесенә, башка төрле вазифаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә имзалатып тапшырыла яисә кулга тапшыру турында белдерүнамә белән, заказлы хат итеп һәм (яки) шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ рәвешендә (тикшерелә торган зат дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге) яки муниципаль контрольлек кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә риза булганда), күрсәтелгән документны алганлыкны раслый торган ысул белән җибәрелә. Шул ук вакытта кулга тапшыру турында белдерүнамә һәм (яки) күрсәтелгән документны алганлыкны алу турында раслый торган башка төрле дәлил ТР ЭТРМ эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.”;

җиденче кызыл юлда “тикшерүләрне исәпкә алу дәфтәрендә” сүзләреннән соң “(булган очракта)” сүзләрен өстәргә”;

5.3.5 пунктының өченче кызыл юлын көчен югалткан дип танырга;

5.4.3 пунктында “боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре алдына “министрның (министр урынбасарының)” сүзләрен өстәргә;

5.4.4 пунктында:

дүртенче кызыл юлда “әмернамәсе” сүзен “боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

бишенче кызыл юлда “боерыгы (әмернамәсе)” сүзләре алдына “министрның (министр урынбасарының)” сүзләрен өстәргә;

5.4.6 пунктының өченче кызыл юлын көчен югалткан дип танырга;

5.4.8 пунктында түбәндәге эчтәлекле кызыл юл өстәргә:

“Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозу буенча ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару турында күрсәтмәне үтәү вакытының узуы нигез булып торса, мондый тикшерүнең предметы булып фәкать Министрлык биргән күрсәтмәнең үтәлеше генә тора ала.”;

6.5 пунктының икенче кызыл юлында “әмернамәсе” сүзен “боерыгы (әмернамәсе)” сүзләренә алмаштырырга;

7.4 пунктының беренче кызыл юлында “Шикаятькә җавап бирелми” сүзләреннән соң “яисә шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылы буенча җавап бирелми” сүзләрен өстәргә;

7.5 пунктында “мәгълүмати-телекоммуникацияләр” сүзен төшереп калдырырга;

Административ регламентның 7.6 пунктында “тиешле гарызнамә язмача” сүзләреннән соң “яки электрон” сүзләрен өстәргә;

1-4 кушымталарда “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар

министрлыгының атмосфера һавасын саклау, шул исәптән атмосфера һавасына пычраткыч матдә һәм башка матдә ташландыклары өчен түләүне контрольдә тоту өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәүнең административ регламентына карата” сүзләрен “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле булган хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында атмосфера һавасын саклау өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазифасын үтәү буенча административ регламентына карата” сүзләре белән алмаштырырга;

Административ регламентның 3 кушымтасындагы дәүләт вазифасын үтәүнең Блок-схемасында “һәм атмосфера һавасына чыгарыла торган пычраткыч матдә һәм башка төрле матдә ташландыклары өчен түләү” сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А.Тронин) шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту өчен министр урынбасары Ф.Ф. Шакировны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев